ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

28 августа 2024г.

**КАРАР**

№ 5580

Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10493 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 31, 36 пунктлары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы Боерыгы белән расланган дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы Боерыгы белән расланган күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә, халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы Карары, Башкарма комитетның

2017 елның 26 декабрендәге 8125 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10493 номерлы Карары кушымтасына, 1 пунктны һәм 4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.07.2024 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак урынны наемга алу өчен түләүнең база күләме | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 8,30* |
| 4.9. | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 0,61 |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе
Ф.Ш. Салахов